**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 25 февраль № 112

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2008 ел, 18 апрель, 246 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2008 ел, 18 апрель, 246 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 24 февраль, 96 нчы; 2009 ел, 5 март, 125 нче; 2010 ел, 20 апрель, 278 нче; 2010 ел, 15 июнь, 477 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 12 август, 663 нче; 2011 ел, 8 сентябрь, 753 нче; 2012 ел, 27 апрель, 329 нчы; 2012 ел, 31 август, 743 нче; 2013 ел, 26 март, 203 нче; 2013 ел, 31 октябрь, 831 нче; 2013 ел, 14 декабрь, 987 нче; 2013 ел, 31 декабрь, 1136 нчы; 2014 ел, 16 апрель, 249 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.1 нче пунктта:

текстка түбәндәге эчтәлекле $4.1.5^1$ нче пунктча өстәргә:

«$4.1.5^1$. Аучылык ресурслары, федераль әһәмияттәге махсус сакланыла торган табигать территорияләрендәге аучылык ресурсларыннан тыш, санын җайга салу.»;

текстка түбәндәге эчтәлекле $4.1.9^1$ нче пунктча өстәргә:

«$4.1.9^1$. Аучылык ресурсларын, федераль әһәмияттәге махсус сакланыла торган табигать территорияләрендәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән аучылык ресурсларыннан тыш, аулауга рөхсәтнамәләр бирү.»;

текстка түбәндәге эчтәлекле 4.1.42[1] нче пунктча өстәргә:

«4.1.42[1]. Хайваннар дөньясы объектларын һәм алар яшәгән мохитне саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы белән килештерелгән хайваннар дөньясы объектларын, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләрендәге хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, кулланыштан алу күләмнәрен (лимитларын) билгеләү.»;

5.4 нче пунктның 5.4.3 нче пунктчасындагы «эшмәкәрлек эшчәнлегеннән һәм керем китерә торган башка эшчәнлектән алынган акча исәбеннән» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\112.doc